# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

"26" ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 13 сәгать 00 минутта һәм 15 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Җирлек территориясен төзекләндерү :
- Чишмәне койма белән әйләндеру (төзелеш материаллары сатып алу , транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Чишмәгә төшү юлына баскыч ясау һәм урнаштыру(төзелеш материаллары сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү.;

2. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:
-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;

3. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- авыл территориясен чистарту, хезмәт өчен түләү.

4. Җирлек территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- электр белән тәэмин итүнең автоном резерв чыганагын сатып алу
(бензогенератор 380 В)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 298 (ике йөз туксан сигез ) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан граҗданнар саны 172 (бер йөз җитмеш ике) кеше, бу 55,66 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 172 (бер йөз җитмеш ике) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Тубән Шашы авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Сез 2022 елда Күңгәр авыл җирлеге Тубән Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым

кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Җирлек территориясен төзекләндерү :
- Чишмәне койма белән әйләндеру (төзелеш материаллары сатып алу , транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Чишмәгә төшү юлына баскыч ясау һәм урнаштыру(төзелеш материаллары сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү.;

2. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:
-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;

3. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- авыл территориясен чистарту, хезмәт өчен түләү.

4. Җирлек территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- электр белән тәэмин итүнең автоном резерв чыганагын сатып алу (бензогенератор 380 В)
Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә. мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Сибгатуллин Д.Р.